ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАМАДЫШ-ӘКИЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

2016 елның 1 сентябре, № 48

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш-Әкил авыл җирлеге муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. 2016 елның 1 февралендәге 25 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмәне түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә::

«9. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләр туктатылган очракта, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 73 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләрендә каралган нигезләр буенча түләнми.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru - Интернет челтәрендә.

Мамадыш-Әкил Авыл Җирлеге Башлыгы
авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе Ф.Ф.Мирхәтуллин